КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 14 апрель г.Казань № 462

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 325 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 ел, 24 февраль, 101 нче; 2009 ел, 9 ноябрь, 776 нчы; 2010 ел, 9 апрель, 253 нче; 2010 ел, 9 июнь, 454 нче; 2010 ел, 10 декабрь, 1038 нче; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2011 ел, 21 февраль, 125 нче; 2011 ел, 25 март, 220 нче; 2011 ел, 13 апрель, 291 нче; 2011 ел, 29 июль, 613 нче; 2011 ел, 13 август, 674 нче; 2012 ел, 30 июль, 646 нчы; 2013 ел, 9 февраль, 80 нче; 2013 ел, 14 март, 163 нче; 2013 ел, 7 октябрь, 730 нчы; 2013 ел, 30 ноябрь, 940 нчы; 2014 ел, 5 февраль, 64 нче; 2014 ел, 29 март, 201 нче; 2014 ел, 11 ноябрь, 853 нче; 2015 ел, 2 февраль, 49 нчы; 2015 ел, 3 июнь, 401 нче; 2015 ел, 20 август, 610 нчы; 2015 ел, 2 октябрь, 733 нче; 2016 ел, 26 февраль, 121 нче; 2016 ел, 25 ноябрь, 874 нче; 2017 ел, 9 февраль, 74 нче; 2017 ел, 10 июль, 468 нче; 2017 ел, 6 ноябрь, 846 нчы; 2017 ел, 30 ноябрь, 930 нчы; 2018 ел, 29 март, 185 нче; 2018 ел, 4 май, 317 нче; 2018 ел, 27 июнь, 523 нче; 2018 ел, 15 декабрь, 1140 нчы; 2019 ел, 16 гыйнвар, 9 нчы; 2019 ел, 4 апрель, 270 нче; 2019 ел, 29 сентябрь, 860 нчы; 2020 ел, 26 март, 220 нче; 2020 ел, 25 май, 424 нче; 2020 ел, 26 август, 744 нче; 2020 ел, 14 октябрь, 924 нче; 2021 ел, 4 май, 306 нчы; 2021 ел, 6 сентябрь, 817 нче, 2022 ел, 5 март, 196 нчы; 2022 ел, 9 июль, 661 нче, 2022 ел, 30 декабрь, 1483 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы турындагы нигезләмәгә, 1.2 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Табигать ресурслары торышы турында һәм Татарстан Республикасы әйләнә-тирә мохитын саклау хакында еллык дәүләт докладын әзерләү турында» 2017 ел, 16 гыйнвар, 9 нчы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Табигать ресурслары торышы турында һәм Татарстан Республикасы әйләнә-тирә мохитын саклау хакында еллык дәүләт докладын әзерләү турында нигезләмәнең 6 пунктында «Татарстан Республикасы Президенты Аппаратына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясенә» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Табигать ресурслары торышы турында һәм Татарстан Республикасы әйләнә-тирә мохитын саклау хакында еллык дәүләт докладын әзерләүдә катнашучылар исемлеген яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә).

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы нефть ятмаларындагы катлам суларын комплекслы файдалануның максатчан программасы турында» 2001 ел, 17 август, 564 нче карарын үз көчен югалткан дип танырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2017 ел, 16 гыйнвар, 9 нчы
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 14 апрель, 462 нче
карары редакциясендә)

Табигать ресурслары торышы турында һәм Татарстан Республикасы әйләнә-тирә мохитын саклау хакында еллык дәүләт докладын әзерләүдә катнашучылар исемлеге

1. «Казэнерго» акционерлык җәмгыяте (килешү буенча).
2. «Түбән Кама техник углерод заводы» акционерлык җәмгыяте (килешү буенча).
3. «РариТЭК Холдинг» акционерлык җәмгыяте (килешү буенча).
4. «Җир» республика кадастр үзәге» акционерлык җәмгыяте (килешү буенча).
5. «Таткоммунэнерго» республика җитештерү берләшмәсе" акционерлык җәмгыяте (килешү буенча).
6. «ТАИФ-НК» акционерлык җәмгыяте (килешү буенча).
7. «Танеко» акционерлык җәмгыяте (килешү буенча).
8. «Татэнерго» акционерлык җәмгыяте (килешү буенча).
9. «ТГК-16» акционерлык җәмгыяте (килешү буенча).
10. «Руда булмаган файдалы казылмалар геологиясенең үзәк фәнни-тикшеренү институты» акционерлык җәмгыяте (килешү буенча).
11. Табигатьтән файдалану өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Идел-Кама төбәкара идарәсе (килешү буенча).
12. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе.
13. Татарстан Республикасының геология һәм җир асты байлыкларыннан файдалану буенча фәнни-җитештерү берләшмәсе» дәүләт бюджет учреждениесе.
14. «Татарстан Республикасында ягулык-энергетика ресурслары сыйфатын һәм рациональ файдалануны тәэмин итү идарәсе» дәүләт бюджет учреждениесе.
15. «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт фәнни бюджет учреждениесе.
16. Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты.
17. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы.
18. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы.
19. Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы.
20. Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы.
21. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына.
22. Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы.
23. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы.

24. Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы.
25. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы.
26. Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы.
27. Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы.
28. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы.
29. Казан шәһәренең «Юл хәрәкәте белән автоматлаштырылган идарә итү системасы» муниципаль казна учреждениесе (килешү буенча).
30. «Газпром трансгаз Казань» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте (килешү буенча).
31. «Казаноргсинтез» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте (килешү буенча).
32. «Түбән Кама ТЭЦ» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте (килешү буенча).
33. «Татшин» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте (килешү буенча).
34. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары (килешү буенча).
35. Техник җайга салу һәм метрология буенча федераль агентлыкның Идел буе-Урал төбәкара территориаль идарәсенең Татарстан Республикасында һәм Удмурт Республикасында бүлеге (инспекция) (килешү буенча).
36. Су ресурслары федераль агентлыгының Түбән Идел бассейны су идарәсенең Татарстан Республикасы буенча су ресурслары бүлеге (килешү буенча).
37. Идел буе федераль округы буенча җир асты байлыкларыннан файдалану департаментының Татарстан Республикасы буенча геология һәм лицензияләү бүлеге (килешү буенча).
38. «Татмелиорация» траст компаниясе» ачык акционерлык җәмгыяте (килешү буенча).
39. Экология, технология һәм атом күзәтчелеге федераль хезмәтенең Идел буе идарәсе (килешү буенча).
40. «КАМАЗ» гавами акционерлык җәмгыяте (килешү буенча).
41. «Түбән Кама Нефтехим» гавами акционерлык җәмгыяте (килешү буенча).
42. В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционерлык җәмгыяте (килешү буенча).
43. «Газпром газ-мотор ягулыгы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьнең урта идел филиалы (килешү буенча).
44. «Бөтенроссия фәнни-тикшеренү балык хуҗалыгы һәм океанография институты» федераль дәүләт бюджет фәнни учреждениесенең Татарстан филиалы (килешү буенча).
45. Федераль дәүләт статистикасы хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча территориаль органы (килешү буенча).
46. Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының Юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясе идарәсе (килешү буенча).
47. Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе җитәкчесе (килешү буенча).
48. Ветеринария һәм фитосанитария күзәтчелеге федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе (килешү буенча).

49. Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеген саклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе (килешү буенча).

50. «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем мәгариф учреждениесе (килешү буенча).

51. «Татар авыл хуҗалыгы фәнни-тикшеренү институты» федераль дәүләт бюджет фәнни учреждениесе (килешү буенча).

52. «Казан дәүләт архитектура-төзелеш университеты» федераль дәүләт автоном югары белем мәгариф учреждениесе (килешү буенча).

53. «Казан дәүләт энергетика университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем мәгариф учреждениесе (килешү буенча).

54. «А.Н.Туполев исемендәге Казан илкүләм тикшеренү техник университеты – КАИ» федераль дәүләт бюджет югары белем мәгариф учреждениесе (килешү буенча).

55. «Казан милли тикшеренү технология университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем мәгариф учреждениесе (килешү буенча).

56. «Татарстан Республикасы гидрометеорология һәм әйләнә-тирә мохитне мониторинглау идарәсе» федераль дәүләт бюджет учреждениесе (килешү буенча).

57. Татарстан Республикасы буенча «Россия авыл хуҗалыгы үзәге» федераль дәүләт бюджет учреждениесе филиалы (килешү буенча).